КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«09» июнь 2021 ел. № 86-п

“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2021 елның 21 апрелендәге 52-п номерлы боерыгы белән расланган “Россия халыкларының милли бәйрәмнәре” гомумроссия фотоконкурсын үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“2014 – 2023 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” дәүләт программасын раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган “2014 – 2023 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында” 2021 елның 29 апрелендәге 297 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары кабул ителүгә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2021 елның 21 апрелендәге 52-п номерлы боерыгы белән расланган “Россия халыкларының милли бәйрәмнәре” гомумроссия фотоконкурсын үткәрү турында нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләрне расларга (кушымта итеп бирелә).

Җитәкче А.С. Сәлимгәрәев

«Татмедиа» республика<br>матбугат һәм массакүләм<br>коммуникацияләр<br>агентлыгының<br>2021 елның «09» июнь<br>86-п_ номерлы<br>боерыгы белән<br>РАСЛАНДЫ

“Россия халыкларының милли бәйрәмнәре”
гомумроссия фотоконкурсын үткәрү турында нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләр

5 бүлектә

5.1. пунктының “д” пунктчасындагы өченче һәм дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык;

тарату өчен персональ белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык;”;

9 бүлектә:

9.2. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Акчалата приз фонды 382,5 мең сум тәшкил итә.”;

9.4. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9.4. Конкурста җиңүчеләр түбәндәге түбәндәге номинацияләрдә премияләр һәм дипломнар белән бүләкләнә:

**“Иң яхшы фото”**

I дәрәҗә диплом һәм 52,5 мең сум;

II дәрәҗә диплом һәм 42,5 мең сум;

III дәрәҗә диплом һәм 32,5 мең сум.

**“Фотоэшләр сериясе”**

I дәрәҗә диплом һәм 52,5 мең сум;

II дәрәҗә диплом һәм 42,5 мең сум;

III дәрәҗә диплом һәм 32,5 мең сум.

**“Портрет”**

I дәрәҗә диплом һәм 52,5 мең сум;

II дәрәҗә диплом һәм 42,5 мең сум;

III дәрәҗә диплом һәм 32,5 мең сум.”;

2 нче кушымтада бит саны астына “Тәкъдим ителә торган форма” сүзләрен өстәргә;

3 нче кушымтада бит саны астына “Тәкъдим ителә торган форма” сүзләрен өстәргә.